**<u>Татар халык җыры</u>**

## Ачма тәрәзәңне

Их, дускаем, айга кара,
Мин дә айга карармын.
Күз нурларың айга төшәр,
Шуннан эзләп табармын.

Ачма тәрәзәңне, мин килмичә!
Ятларны сөярсең белмичә...

Их, дускаем, матуркаем,
Сагынам сине көн саен;
Һәр кичләрен айга карап,
Эзлим йолдызлар саен.

Ачма тәрәзәңне, мин килмичә!
Ятларны сөярсең белмичә...

Ач тәрәзәң, күтәр пәрдәң,
Нурлы йөзең күренсен.
Сөймәс булсаң, әйт үземә,
Минем күңелем сүрелсен.

Ачма тәрәзәңне, мин килмичә!
Ятларны сөярсең белмичә...